| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

21.11.2018 Казан ш. № 10-53/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 14 апрелендәге 10-9/кс номерлы карары белән билгеләнгән "Сток" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 елга ташландык суны чыгаруга озак вакытка исәпләнгән чик тарифларны үзгәртү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы, "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны билгеләү регламентын раслау турында" 2014 елның 16 июлендәге 1154-э номерлы боерыклары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, "Сток" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ташландык суны чыгаруга озак вакытка исәпләнгән тарифларын һәм таләп ителгән тулаем табышын үзгәртү максатларында Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "2017 – 2020 елларга "Сток" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык суны чыгаруга тарифлар билгеләү турында" 2017 елның 14 апрелендәге 10-9/кс номерлы карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 1 декабрендәге 10-54/кс номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 14 апрелендәге 10-9/кс номерлы карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 21 ноябрендәге 10-53/кс номерлы карары редакциясендә)

## Ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "Сток" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2017 – 2020 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, ташландык суны чыгаруга тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ташландык суларны чыгаруга билгеләнгән тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | карар үз көченә кергән көннән алып 2017 елның 30 июненә кадәр | 2017 елның 1 июленнән алып 2017 елның 31 декабренә кадәр | 2018 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 декабреннән алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр |
| | Кукмара муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | "Сток" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 29,23 | 30,34 | 30,34 | 31,55 | 31,55 | 32,28 | 32,28 | 33,18 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 14 апрелендәге 10-9/кс номерлы карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 21 ноябрендәге 10-53/кс номерлы карары редакциясендә)

Ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "Сток" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2017 – 2020 елларга ташландык суны чыгаруга тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| т/б № | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме, тариф төре | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт.сәг./куб. м |
| 1 | "Сток" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Ташландык суны чыгару | 2017 | 6194,10 | 1 | - | - | 2,1 |
| | | 2018 | 6270,97 | 1 | - | - | 2,1 |
| | | 2019 | 6 493,83 | 1 | - | - | 2,1 |
| | | 2020 | 6 647,48 | 1 | - | - | 2,1 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге